КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 февраль г.Казань № 77

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән расланган 2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 ноябрь, 1056 нчы; 2021 ел, 23 ноябрь, 1111 нче; 2022 ел, 18 май, 460 нчы; 2022 ел, 29 октябрь, 1151 нче; 2023 ел, 17 февраль, 151 нче; 2023 ел, 20 июль, 870 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2028 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә 2024 елның 1 мартына кадәр 2023 елга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планы үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин